**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4635**
**17.08.2018**

Яр Чаллы шәһәренең «12 санлы Олимпия резервы» махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсе 1 бүлеге 4 пункты, шәһәр Уставының 41, 53, 55 маддәләре, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары, Башкарма комитетның «Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезнамәне раслау хакында» 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «12 санлы Олимпия резервы» махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастыруны һәм Татарстан Республикасының (pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                 Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 17 августындагы
4635 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«12 санлы Олимпия резервы» махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| 1. | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Спорт залына абонемент (укучылар) | бер ай | 300,00 |
| 2. | Спорт залына абонемент (студентлар) | бер ай | 500,00 |
| 3. | Спорт залына абонемент (зурлар) | бер ай | 700,00 |
| 4. | Спорт залы хезмәтләре | бер сәгать | 75,00 |
| 5. | Массакүләм спорт чаралары оештыру һәм үткәрү | бер сәгать | 1000,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова